**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023 елның12 мае 1566 номер

**КАРАР**

**«Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2003 елның 28 июлендәге 2021 номерлы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2013 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2004елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы"белән (03.02.2023ел үзәртүләр һәм өстәмәләр белән үз көченә кергән) карар бирәм:

1) «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2003 елның 28 июлендәге 2021 номерлы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2) Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.Ә. Нурмөхәммәтов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районы Башкарма комитетының
2023 елның«12» маендагы
1566 номерлы карарына кушымта

«Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2003 елның 28 июлендәге 2021 номерлы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү

**1) 2.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турындагы гаризада күрсәтелгән булса, республика порталының шәхси кабинетына электрон документ рәвешендә җибәрелә.

**2) 2.7.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Регламентка 4 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелә, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Республика порталының һәм (яисә) МФЦда муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар кабул ителгән көнне шәхси кабинетына җибәрелә.

**3) 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы - 14 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң икенче көнгә исәпләнә башлый.